

# Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган “Туган тел” мастер-класс бәйгесе

## Туган җирем,

## мәктәбем,

## һөнәри эшчәнлегем.



**Бурганова Гөлнара Нәсим кызы,**

**Тукай муниципаль районы МБГББУ «Калмаш урта гомуми белем мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

# Мин Калмаш авылында туганмын








**Сез кайдан дип сорасагыз – без Калмаштан,**
**Моңнар алдык чишмәләрдән, сандугачтан.**
**Татар моңы ишетелә һәр тарафтан,**
**Моңлы илем туган җирем “Татарстан”.**




# *Минем мәктәбем*



Мин, Бурганова Гөлнара Нәсим кызы, Калмаш мәктәбендә 2009 нчы елдан бирле татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшлим.

# Минем укучыларым



Сорау тулы күзләр сиңа карый.
Бер сораумы, йөзме, меңәүме?
“Белмим” сүзен  әйтә күрмә!
Кичермиләр алар белмәүне.

Син – укытучы, белергә тиеш,
Ни сорыйлар, шуны белергә.
Укытучы булу – шундый эш –
Белгәнеңне кирәк бирергә.




ПОЖАРНАЯ
БЕЗОПАСНОСТЬ







**Укучыларым дәресләрендә алган белемнәрен район, зона һәм республика олимпиадаларында сынап карыйлар һәм призлы урыннарга да лаек булалар.**

*Укысыннар, бар да белем алсын*
*Туган телем – татар телендә.*
*Туган телен сөйгән кеше генә*
*Бәхет яулый туган илендә.*



Матур хыял, якты идеалларым
Сиңа бәйле, сөйгән мәктәбем.
Онытылмаслык истәлекләр белән
Тулы минем күңел дәфтәрем.
Үткән юллар, тормыш мәшәкате
Маңгаема сырлар сызса да,
Йөрәгемнән чыкмыйсың бит, мәктәп,
Чәчләремә чаллар керсә дә.
 Олы бәхет – бөтен гомереңне
Яшь буынга биру, багышлау,
Илең-халкың белән бергә атлау,
Тормыш агышыннан калышмау.
Җиргә лаек итеп уллар, кызлар
Тәрбияләү нинди куаныч!
Укытучы өчен моңардан да
Бармы икән олы юаныч?!

# Игътибарыгыз өчен рәхмәт!